**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «28» июненән № 36

2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләүне һәм үткәрүне оештыру турында

"Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында" 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны оештыру турында" 2020 елның 29 августындагы 1315 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләүне һәм үткәрүне оештыру турында" 2020 елның 30 декабрендәге 1265 номерлы карары нигезендә һәм 2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия турында кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне һәм комиссиянең составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә 2021 елда авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле мәсьәләләр буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсен билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Яңа Чишмә муниципаль районындагы территориаль органына, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу мәгълүматлары нигезендә, 2021 елның 1 гыйнварына актуальләштерелгән җир мәйданын һәм терлекләрнең баш санын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшәүче җирдән файдаланучылар турында белешмәләр бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Яңа Чишмә районындагы территориаль органына авыл җирлекләре территорияләрендә яшәүче гражданнарны авыл хуҗалыгы исәбенә алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүдә, шулай ук авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыючы затларны укыту һәм эшкә яраклы урыннар сайлауда, исәпкә алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклауда ярдәм итәргә;

2021 елда административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп коруны, шулай ук географик объектларның исемнәрен үзгәртүне гамәлгә ашырмаска.

5. «Татмедиа» АҖ филиалына авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрүне мәгълүмати яктырту, авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эшләре алып барырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2021 елның «28» июнендәге
№ 36 карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба-ведомствоара комиссия, авыл хуҗалыгы исәбен алу) "Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында" 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2021 елгы авыл хуҗалыгы санын алуны оештыру турында" 2020 елның 29 августындагы 1315 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Яңа Чишмә авылындагы территориаль органына, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда башка территориаль органнарына ярдәм күрсәтү максатларында төзелде.

1.2. Ведомствоара комиссия авыл хуҗалыгы санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен төзелгән коллегиаль орган булып тора.

1.3. Ведомствоара комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларына таяна, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә эш итә.

## II. Ведомствоара комиссиянең бурычлары

2.1. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча

килешенгән гамәлләрен (үзара хезмәттәшлеген) тәэмин итү;

авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны уздыру белән бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү;

Яңа Чишмә муниципаль районы халкы арасында авыл хуҗалыгы санын алу турында мәгълүмати-аңлату эшләрен алып бару.

2.2. Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне карый:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында үзара хезмәттәшлеге.

## III. Ведомствоара комиссия хокуклары

3.1. Төп бурычларны тормышка ашыру өчен ведомствоара комиссия хокуклы:

үз утырышларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында тыңлау;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча кирәкле материалларны соратып алырга;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча рекомендацияләр җибәрергә.;

ведомствоара комиссия эшенә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, фәнни һәм иҗтимагый оешмалар, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итәргә.

## IV. Ведомствоара комиссия составы

4.1. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

4.2. Ведомствоара комиссия комиссия рәисеннән, аның урынбасарыннан, ведомствоара комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

4.3. Ведомствоара комиссия составына федераль җирле үзидарә органнарының территориаль органнары, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керә.

## V. Ведомствоара комиссиянең эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән рәис җитәкчелек итә. Ведомствоара комиссия рәисе булмаганда, аның функциясен ведомствоара

комиссия рәисе урынбасары башкара.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр уздырыла.

5.3. Ведомствоара комиссия рәисе (рәис булмаганда, урынбасары) мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен раслый, ведомствоара комиссия составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышларының көн тәртибе, авыл хуҗалыгы санын алуны үткәрү буенча эш планы нигезендә, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Яңа Чишмә авылындагы территориаль органы тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

5.5. Ведомствоара комиссия әгъзалары ведомствоара комиссия утырышларында шәхсән катнашалар һәм ведомствоара комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәиснең тавышы (ул булмаганда, урынбасары) хәлиткеч булып тора.

5.8. Ведомствоара комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар ведомствоара комиссия утырышы беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә. Карарларга ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаганда, утырышта рәислек итүче урынбасары) кул куя.

5.9. Ведомствоара комиссия эшен оештыру-техник яктан тәэмин итү Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы Яңа Чишмә авылы буенча территориаль органы тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2021 елның «28» июнендәге
№ 36 карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә
2021 елгы авыл хуҗалыгы исәбен алуга
әзерлек һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия составы

Ведомствоара комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Козлов Вячеслав Михайлович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы |

Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Богомолов Леонид Евгеньевич | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

Ведомствоара комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Прыткова Валентина Александровна | - | Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Яңа Чишмә районындагы территориаль органы әйдәп баручы белгеч-эксперты, авыл хуҗалыгы исәбен алу буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Жирнов Эдуард Алексеевич | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлекчәсе начальнигы (килешү буенча) |
| Исхакова Луиза Камил Кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Козлова Оксана Витальевна | - | дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Аксубай, Яңа Чишмә һәм |

| | | |
|---|---|---|
| | | Чирмешән районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы урынбасары (килештерү буенча) |
| Лаврентьева Ольга Александровна | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы |
| Мусин Азат Вәлиҗан улы | - | «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – "Яңа Чишмә хәбәрләре" газетасы редакциясенең баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Попкова Наталья Владимировна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |